РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

02.11.2021 ел №67

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Район халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру буенча вәкаләтләрнең бер өлешен кабул итү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ивашкино, Мордва Афонькәсе, Түбән Кәминкә, Туймәт авыл җирлекләре вәкиллекле органнарының Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына Чирмешән муниципаль районы авыл җирлекләре башкарма комитетлары вәкаләтләрен район халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру буенча тапшыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы башкарма комитетына:

- Чирмешән муниципаль районының Ивашкино, Мордва Афонькәсе, Түбән Кәминкә, Туймәт авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрнең бер өлешен Кушымта нигезендә типлаштырылган формасы нигезендә тапшыру турында килешүләр төзергә, төзелә торган килешүләрнең гамәлдә булуы 2002 елның 2 ноябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип күздә тотып;

- әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатыннан, Финанс-бюджет палатасына, бюджет законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының 2021 елга һәм 2022, 2023 еллар план чорына Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджеты

турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карары проектын эшләргә һәм карарга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту район Советының икътисади сәясәт һәм бюджет буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Муниципаль район башлыгы,
Совет рәисе Ф.М. Дәүләтшин

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Советы карарына кушымта
02.11.2021 ел №67

**Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитетына район халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру буенча _________________ авыл җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында килешү**

**Чирмешән авылы** **«____»________2021ел**

___________ авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе исеменнән эш итүче__________ авыл җирлеге башкарма комитеты, алга таба «Авыл җирлеге башкарма комитеты» дип аталучы, Устав нигезендә гамәл кылучы, бер яктан һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Шәйдуллин Илфат Нәгыймулла улы исеменнән эш итүче__________ муниципаль районы башкарма комитеты, алга таба - «район Башкарма комитеты» дип аталучы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә таянып, әлеге Килешүне түбәндәгеләр турында төзеделәр:

1. Килешү предметы

1.1. Әлеге Килешү авыл җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны район башкарма комитетына тапшыруны беркетә.

1.2. Авыл җирлеге башкарма комитеты район башкарма комитетына халыкның ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру буенча вәкаләтләрне тормышка ашыруны тапшыра.

2. Акча чаралары күләмен билгеләү тәртибе

2.1. Әлеге Килешү предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру Чирмешән муниципаль районы бюджетына _________ авыл җирлеге бюджеттан бирелә торган акчалар хисабына гамәлгә ашырыла.

2.2. Әлеге килешүнең 1.2 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Чирмешән муниципаль районы бюджетына ____________ авыл җирлеге бюджетыннан бирелә торган акчаларны формалаштыру, күчерү һәм исәпкә алу Россия Федерациясе Бюджет законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Якларның хокуклары һәм бурычлары

3.1. Район башкарма комитеты әлеге килешүнең 1 бүлеге һәм гамәлдәге

законнар нигезендә үзенә җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне башкара.

3.2. Яклар әлеге Килешүне гамәлгә ашыру кысаларында Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы закон һәм норматив хокукый актларында каралган срокларда һәм күләмнәрдә мәгълүмат алмашырга бурычлы.

3.3. Җирлек башкарма комитеты район башкарма комитетына тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен һәм вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен бирелгән финанс чараларының максатчан кулланылышын контрольдә тота ала.

## 4. Килешүнең гамәлдә булу вакыты, нигезләре һәм гамәлдә булуын туктату тәртибе

4.1. Әлеге Килешү Чирмешән муниципаль районы Советы тарафыннан расланганнан һәм яклар тарафыннан имзаланган көннән үз көченә керә.

Килешү 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә.

4.2. Әлеге килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылырга мөмкин:

4.2.1. Якларның килешүе буенча.

4.2.2. Берьяклы тәртиптә:

- әгәр вәкаләтләрне гамәлгә ашыру мөмкин булмаган булса, шул исәптән Россия Федерациясе законнары һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары үзгәргән очракта да;

- авыл җирлеге башкарма комитеты инициативасы буенча, район Башкарма комитеты тарафыннан аңа тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә башкармау (яки гамәлгә ашырмау) факты ачыкланган очракта, икенче якка бер ай алдан хәбәр итү шарты белән субвенцияне максат буенча кулланмау очрагында.

4.3. Килешүне өзү язма рәвештә теркәлә.

## 5. Якларның җаваплылыгы

5.1. Яклар гамәлдәге законнар нигезендә әлеге Килешүдә каралган бурычларны тиешенчә үтәмәгән өчен җаваплы.

5.2. Район Башкарма комитеты тарафыннан аңа тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә башкармау фактын билгеләү әлеге килешүне берьяклы өзүгә нигез булып тора. Килешүне өзү документта расланган факттагы чыгымнарны исәпкә алып, күчерелгән субвенцияләрне килешүне өзү яки өзелү турында язма хәбәр алынганнан соң 30 көн эчендә кире кайтаруга китерә.

5.3. Район башкарма комитеты үзенә тапшырылган вәкаләтләрне тормышка ашыру өчен, бу вәкаләтләр финанс чаралары белән тәэмин ителгән дәрәҗәдә җаваплылык тота.

5.4. Әлеге килешүдә каралмаган якларның җаваплылык чаралары Россия Федерациясе территориясендә гамәлдә булган граждан законнары нормалары нигезендә кулланыла.

## 6. Башка мәсьәләләр

6.1. Яклар үзара килешүе буенча яисә гамәлдәге закон таләпләре нигезендә әлеге килешүгә яклар кул куйганнан соң, әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булган язма рәвештә үзгәрешләр һәм (яки) өстәмәләр кертелергә мөмкин.

6.2. Әлеге Килешүне үтәгәндә яклар тарафыннан җайга салынмаган бәхәсләр һәм каршылыклар гамәлдәге законнарда каралган тәртиптә каралырга тиеш.

6.3. Әлеге Килешү 2 (ике) нөсхәдә, һәр як өчен тигез юридик көчкә ия берәр нөсхәдә төзелде.

7. Якларның адреслары һәм башка мәгълүматлар

| | |
|---|---|
| «Авыл җирлеге башкарма комитеты» | «Район башкарма комитеты» |
| ___________ авыл җирлеге башкарма комитеты | ___________ муниципаль районы башкарма комитеты |
| ___________________ (имза) ________________ (ФИА) | ____________________ (имза) ______________ (ФИА) |